# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пунктында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**26.11.2021ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2022 елда 600 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Иске Иркәнәш торак пунктында (Тукай урамы, 1 Май урамы, Совет урамы, Имәнле урамы);авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Иркәнәш торак пунктында зират өчен инвентарь (чүкеч һәм генератор) сатып алу.

3. Әлеге карарны Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы ____________ Камалов И. З.
(имза) (имзаны киңәйтү)